КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 16 ноябрь г.Казань № б-2460

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм аларның эшчәнлеге өлкәсенә караган оешмалар биләгән, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган террорчылыктан саклануга карата таләпләр көченә туры килми торган объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан саклануны тәэмин итү максатларында, шулай ук Милли террорчылыкка каршы комитетның тәкъдимнәрен тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм аларның эшчәнлеге өлкәсенә караган оешмалар биләгән административ биналарның (Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган террорчылыктан саклануга карата таләпләр кагыла торган биналар категорияләреннән тыш) террорчылыктан сакланышын тәэмин итү буенча тәкъдимнамәләрне (боерыкка теркәлә) расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 16 ноябрь, б-2460 нчы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм аларның эшчәнлеге өлкәсенә караган оешмалар биләгән административ биналарның (Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган террорчылыктан саклануга карата таләпләр кагыла торган биналар категорияләреннән тыш) террорчылыктан сакланышын тәэмин итү буенча
тәкъдимнамәләр

1. Әлеге Тәкъдимнамәләр Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм аларның эшчәнлеге өлкәсенә караган оешмалар (алга таба – Хакимият органнары, оешмалар) файдаланган технологик һәм техник үзара бәйләнгән биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм системалар, аерым биналар, төзелмәләр һәм корылмалар, алар янындагы территорияләр (алга таба – объектлар (территорияләр)) комплексларының террорчылыктан сакланышын тәэмин итү буенча оештыру, инженерлык-техник һәм башка чараларны билгели.

2. Объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итү өчен җаваплылык хуҗалык алып бару, оператив идарә итү яки түләүсез файдалану шартнамәләре нигезендә файдаланган Хакимият органнары, оешмалар җитәкчеләренә, шулай ук объектларда (территорияләрдә) хезмәткәрләр эшчәнлеге белән турыдан-туры җитәкчелек итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларга йөкләнә.

3. Объектлар (территорияләр) өчен мөмкин булган террорчылык куркынычы янауларның төп төрләре:

а) яулап алу куркынычы – объектка һөҗүм итү мөмкинлеге (сәяси, идеологик яки башка таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү өчен объект һәм (яки) заложниклар алу максаты белән);

б) шартлау куркынычы – күп сандагы кешеләргә зыян салу максаты белән объектта (территориядә) яки аның янында шартлаткыч җайланмалар кую;

в) куркыныч матдәләр белән зарарландыру куркынычы – биналарда (корылмаларда) яки алар янындагы территорияләрдә агулый торган, радиоактив һәм кешеләр тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч башка матдәләр куллану мөмкинлеге.

4. Объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан сакланышының төп максатлары:

а) хокук саклау органнары һәм башкарма хакимият органнары белән берлектә, террорчылык актларын кылуга ярдәм итә торган шартларны ачыклау һәм бетерү;

б) террорчылык актларын әзерләү фактларын үз вакытында билгеләү;

в) террорчылык актлары салган зыяннарны минимальләштерү һәм (яки) бетерү.

5. Объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан сакланышы түбәндәгеләр белән тәэмин ителә:

а) террорчылык актларын әзерләү фактларын ачыклауга, шулай ук аларның

нәтиҗәләрен бетерүгә һәм минимальләштерүгә юнәлдерелгән оештыру, инженерлык-техник һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыру;

б) саклау, үткәрү режимын һәм объектның (территориянең) иминлеген тәэмин итүче мәсьәләләрне җайга сала торган хокукый актлар әзерләү;

в) каравыл оештыру һәм чит затларның хокуксыз үтеп керүенә һәм террорчылык актларын кылырга тырышуга каршы килә торган объектка (территориягә) үткәрү режимын билгеләү;

г) объектны саклый торган инженерлык-техник чаралар булу һәм аларның төзеклеге;

д) террорчылыктан саклану буенча документлардан (мәгълүматлардан) чит затларның файдалануын булдырмау;

е) террорчылыкка каршы эшчәнлек өчен билгеләнгән көчләрне һәм чараларны файдалануга даими әзер булуны тәэмин итү.

6. Объектның (территориянең) террорчылыктан сакланышы түбәндәгеләргә юнәлдәрелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру юлы белән тәэмин ителә:

а) объектка (территориягә) хокуксыз үтеп керүгә каршылык күрсәтүгә;

б) объектта (территориядә) билгеләнгән үткәрү режимын һәм объект эчендәге режимны бозучыларны һәм (яки) террорчылык актын кылырга әзерләнү яки аны кылу билгеләрен ачыклауга;

в) объектта (территориядә) террорчылык актын кылырга омтылуларны туктатуга;

г) объектта (территориядә) террорчылык актын кылуның зыяннар салу мөмкинлеген минимальләштерүгә һәм аны кылу куркынычын бетерүгә.

7. Объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан сакланышын тиешле дәрәҗәдә тәэмин итү максатларында түбәндәге чаралар гамәлгә ашырыла:

а) объектның (территориянең) террорчылыктан сакланышы буенча чаралар үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү;

б) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 26 октябрь, б-2399 номерлы боерыгы белән расланган Кешеләр күпләп була торган объектларны видеокүзәтү камералары белән җиһазландыруга карата тәкъдимнамәләр нигезендә, куела торган камералар санын һәм аларны урнаштыру урыннарын исәпкә алып, потенциаль куркыныч участокларны һәм объектның (территориянең) критик элементларын өзлексез видеокүзәтүне, мәгълүматларны архивлаштыруны һәм кимендә 1 ай саклауны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган видеокүзәтү системасы белән җиһазландыру;

в) объектның (территориянең) террорчылыктан сакланышы буенча чараларның үтәлешен тикшерүдә тотуны тәэмин итү;

г) мәгълүмати куркынычсызлыкны тәэмин итүне оештыру, объектның (территориянең) мәгълүмат ресурсларыннан рөхсәтсез файдалану мөмкинлеген юкка чыгара торган чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

д) объектка (территориягә) тыелган предметларны (радиоактив, шартлаткыч, агулый торган матдәләр, кораллар, сугыш кирәк-яраклары, наркотик чаралар һәм башка куркыныч предметлар һәм матдәләр) алып керергә тырышуларны үз вакытында ачыклау;

е) инженерлык-техник чараларны төзек хәлдә тоту һәм объектны (территорияне) өзлексез һәм тотрыклы элемтә белән тәэмин итү;

ж) террорчылыкка каршы тору мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән хезмәттәшлекне оештыру;

з) террорчылык актын кылу куркынычы турында яки аны кылу турында үз вакытында ачыклау һәм әлеге мәгълүматны Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә һәм Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә кичекмәстән җиткерү;

и) террорчылык актын кылу куркынычы йә аны кылу турында мәгълүмат алган очракта, объекттагы (территориядәге) хезмәткәрләрне, шулай ук анда булучыларны (пациентларны) эвакуацияләү тәртибен эшләү;

к) объекттагы (территориядәге) хезмәткәрләргә террорчылык актын кылу куркынычы янаганда яки аны кылганда саклану һәм гамәлләр кылу ысулларын өйрәтү. Объектлардагы (территорияләрдәге) хезмәткәрләр белән дәресләр аларның җитәкчеләре тарафыннан оештырыла. Дәресләр үткәрүгә Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең территориаль органы белгечләре җәлеп ителергә мөмкин;

л) биналардан (корылмалардан) объекттагы (территориядәге) хезмәткәрләрне һәм аларда булучыларны куркынычсыз һәм үз вакытында эвакуацияләү буенча өйрәнүләр, күнегүләр үткәрү. Террорчылык куркынычы дәрәҗәләрен билгеләгәндә гамәлләр планнары нигезендә Хакимият органнары, оешмалар җитәкчеләре тарафыннан үткәрелә;

м) объекттагы (территориядәге) хезмәткәрләргә һәм анда булучыларга биналардан (корылмалардан) куркынычсыз һәм тоткарлыксыз эвакуацияләнү турында үз вакытында хәбәр итү, эвакуациянең техник мөмкинлекләрен тәэмин итү;

н) объектта (территориядә) үткәрү режимын һәм объект эчендәге режимын оештыру һәм тәэмин итү, аларның эшчәнлеген тикшерүдә тоту;

о) визуаль тикшерү чаралары белән (стационар (кул) металл детекторы, тикшерү көзгесе һ.б.) җиһазландыру;

п) хокук саклау органнары хезмәткәрләрен ашыгыч чакыру мөмкинлеген күздә тота торган тревога сигналы белән үзәк каравыл постын җиһазландыру;

р) объектка (территориягә) хокуксыз үтеп керү сәбәпләрен ачыклау, кисәтү һәм бетерү буенча чаралар комплексын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

с) террорчылык характерындагы җинаятьләрне кылуга юнәлдерелгән затларның гамәлләрен үз вакытында ачыклау, кисәтү һәм бетерү;

т) объектка (территориягә) затларның һәм автотранспорт чараларының рөхсәт белән керүен оештыру;

у) объектта (территориядә), шул исәптән объектка (территориягә) якын урнашкан урында чит затларның һәм транспорт чараларының контрольсез булуына юл куймау;

ф) объектны (территорияне), аның биналарын, җир асты коммуникацияләре системаларын, автотранспортны куеп тору урыннарын әледән-әле карап чыгу һәм

тикшерү, шулай ук склад урыннарында даими тикшерүләр үткәрү.

8. Объектта (территориядә) террорчылык акты кылу куркынычы ачыкланганда, объектта (территориядә) террорчылык акты кылу куркынычы турында мәгълүмат (шул исәптән аноним) алганда яки объектта (территориядә) террорчылык акты кылынганда, объекттагы (территориядәге) хезмәткәрләр эшчәнлеге белән турыдан-туры җитәкчелек итүче вазыйфаи зат (алга таба – оешма җитәкчесе) яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат бу турыда Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә кичекмәстән хәбәр итә.

9. Әлеге Тәкъдимнамәләрнең 8 пункты нигезендә объектта (территориядә) террорчылык акты кылу куркынычы турындагы яки аны кылу турындагы мәгълүматны элемтә чаралары ярдәмендә җибәргәндә мәгълүмат тапшыручы зат түбәндәгеләрне хәбәр итә:

а) үз фамилиясен, исемен, атасының исемен (булганда) һәм били торган вазыйфасын;

б) объектның (территориянең) исемен һәм аның төгәл адресын;

в) террорчылык актын кылу куркынычы турында яки аны кылу турында мәгълүмат алу датасын һәм вакытын;

г) террорчылык актын кылу куркынычы турындагы мәгълүматның характерын яки кылынган террорчылык акты характерын;

д) объекттагы (территориядәге) кешеләр санын;

е) Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе соравы буенча башка әһәмиятле мәгълүматларны.

10. Террорчылык актын кылу куркынычы турында яки аны кылу турында мәгълүмат биргән зат мәгълүматны кабул иткән затның фамилиясен, исемен, атасының исемен (булганда), шулай ук аны тапшыру датасын һәм вакытын терки.

Мондый мәгълүмат факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып җибәрелгәндә мәгълүматны тапшыручы зат әлеге хәбәрне үз имзасы белән раслый.

11. Объектта (территориядә) террорчылык акты кылу куркынычы билгеле булганда яки террорчылык актын кылу куркынычы турында мәгълүмат алганда оешма җитәкчесе түбәндәгеләрне тәэмин итә:

а) барлыкка килә торган террорчылык куркынычына карата үз вакытында һәм адекват чара күрүне, объектка (территориягә) каршы юнәлдерелгән террорчылык актларын кылуны кисәтү максатларында терроризмга каршы торуны көчәйтү чараларын гамәлгә ашыруны;

б) объекттагы (территориядәге) затларга террорчылык актын кылу куркынычы

турында хәбәр итүне;

в) кешеләрне эвакуацияләүне;

г) каравылны, шулай ук үткәрү режимын һәм объект эчендәге режимны көчәйтүне;

д) объектка (территориягә) Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгына караган оператив бүлекчәләрнең керү мөмкинлеген оештыруны.